ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 294 от «07» 08 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 20 ноябрендәге «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында» 1622 нче карары белән расланган «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасына үзгәрешләр кертү хакында

Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы тору системасын камилләштерү, коррупциячел хокук бозуларны кисәтүгә ярдәм итүче чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасвы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 20 ноябрендәге «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында» 16922 нче карары белән расланган «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасына (05.02.2024 ел, № 478; 27.06.2022 ел, № 180; 06.10.2021 ел, № 328; 28.07.2020 ел, №267; 05.09.2019 ел,№ 231; 21.11.2018, № 578 ел; 05.09.2018 ел, №474; 11.05.2016ел, № 469 карарлардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1 1 нче пунктта исемендәге «2015-2024» санннарын «2015- 2027» саннарына алмаштырырга:

1.2. «2015-2026 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру муниципаль

0000012303

программасы» ның исемендә (алга таба - Программа) «2015-2026» саннарын «2015-2027» саннарына алмаштырырга;

1.3. Программаның паспортында: - «Программаның исеме» юлында «2015-2026» сананарын «2015-2027» саннарына алмаштырырга; «Программаны гамәлгә ашыру сроклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: 2015-2023 елларның 1 этабы; 2024-2027 еллар -2 этабы.

1.4. «2015-2027 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче В.И. Никитин